КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 776

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 19 июль, 509 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 7 июнь, 479 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәте сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 нче пунктның унөченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.21 һәм 4.22 нче пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спортның олимпиягә кермәгән төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәтенең сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 29 декабрь, 1129 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 июнь, 488 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Спортның олимпиягә кермәгән төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәтенең сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 нче пунктның унөченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.21 һәм 4.22 нче пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин